

НИКОЛАЙ ИВАНОВИЧ ЛОБАЧЕВСКИЙ.

# НИКОЛАЙ ИВАНОВИЧ ЛОБАЧЕВСКИЙ

Неэвклид геометриясен тудыручы бөек рус математигы Николай Иванович Лобачевский гасырлар буе килгән традицияләрне кыю ватучы фән корифейлары арасында мактаулы урын алып тора. Лобачевскийның геометриясе пространство турындагы аңыбызны чиксез киңәйтте, тирәнәйтте, һәм тулыландырды, танып-белү теориясен баетты. Ломоносов кебек үк, Н. И. Лобачевский үз эпохасын йөз елга диярлек алга узып китте. Аның эшләренең бөтен әһәмияте XX йөздә генә чын-чыннан баяланде. Аның чырае — безгә, киләчәк буыннарга, хакыйкатьне ачуы турында хәбәр иткән гениаль акыл иясе һәм батыр йөрәкле кешенең чырае — совет кешеләренең аңына — бигрәк тә бөегрәк һәм гүзәлрәк булып кереп утыра.

Н. И. Лобачевский яшьләрне тәрбияләү турында университет яшьләренә сөйләгән үзенең бик шәп речендә[1] болай диде:

— Миннән соңрак туган кешеләр, сез миннән бәхетлерәк!

Бу сүзләрдә тирән ялгызлык пошынуы белән бергә кешелек дөньясының якты киләчәгенә нык ышану да яңрый иде.

Н. И. Лобачевскийнең тормыш юлы — фәнгә, халык мәгарифенә, җәмагать интересларына аеруча намуслы рәвештә, сүз тидермәслек яхшы итеп хезмәт итүнең үрнәге булып тора. Николай Иванович 1793 нче елның 22 нче октябрендә Нижний Новгород шәһәрендә өяз архитекторы семьясендә туа. Лобачевскийлар семьясе

---

[1] Казан университеты каршында чыгарылган «Казанский вестник», XXXV т., 8 нче китап, 1832 ел, 578—96 битләр.

һәрвакыт мохтаҗлыкта яши, ә 1797 нче елда атасы үлгәннән соң аларның тормышы хәерчелек дәрәҗәсенә барып җитә. Алган тәрбиясе өчен Николай Иванович үзенең анасы — Прасковья Александровнага бурычлы (ул 1840 нчы елда Казанда үлә). Анасы бөтенләй укымаган диярлек, ләкин үз балаларын кайнар сөю белән сөюче, тормыш авырлыкларын түземлек белән күтәрүчән энергияле хатын була. Бары тик аның үтенүләре һәм артыннан йөрүләре аркасында гына Николай Ивановичны һәм аның ике туганын — Александрны һәм Алексейне — 1802 нче елда Казан гимназиясенә казна хисабына урнаштырып булган [1].

Николай Иванович Лобачевский Казан университетында лекцияләрне 1807 нче елның 9 нчы январендә тыңлый башлый, ә шул ук елның 14 нче февралендә студент итеп раслана. Ул энергияле җитез егет була. Куе аксыл чәчләре аның чиста киң маңгаен бизәп торалар. Йөзе еш кына шаян елмаю белән балкый, күзләрендә ирония чаткылары уйнаклап тора. Ул вакыт-вакыт кинәт уен-көлкегә бирелә, студентларның яшерен эшләнгән төрле күңел ачкыч эшләрендә бик теләп катнаша.

Университетка кергәндә ул математика лекцияләренә язылмый, чөнки физика-математика факультетында гимназиядә үтелгәннәр кабатлана. Лобачевский боларның барсын да бик яхшы белә. Аның турында Петроградка университет ректоры Яковкин: «Студент Лобачевскийнең үзен медицина факультетына хәзерләве ачык сизелә» — дип яза. Ләкин ректор ялгыша. Лобачевский бик күп нәрсә белән кызыксына. Анда энергия ташып тора, чыгарга юл эзли. Кондуит исемлеге аның эшләгән гаепләре белән чуарланып беткән була. Бер вакытны Лобачевский төнге 11 сәгаттә университет ишек алдында ракета җибәрә. Бөтенесе куркышалар. Яшь пиротехникны моның өчен карцерга ябалар.

Икенче бер вакытта, «камерный студент» булгач инде, 1810 нчы елны святкалар вактында, ректор тыюына карамастан, ул ике тапкыр маскарадка бара. Лобачевскийне «камерный студент» булудан һәм яхшы укыганы өчен китаплар алуга бирелергә тиеш булган 60 сумнан

[1] Гимназиягә кергән елны Николай Ивановичның абыйсы Александр суга батып үлә. Кечесе — Алексей гимназияне һәм университетны тәмам итә. Соңыннан ул Казан университетында технология адъюнкты булып эшли.

мәхрум итәләр. Студентлар инспекторының ярдәмчесе Кондырев Лобачевскийгә «тискәре, үз гаебен танымаучан, үз турында күп хыялланучан» дип аттестация бирә.

«Үз турында күп хыялланган» егет илһам белән эшли белгән. Бу — Европадагы азатлык хәрәкәтенең тәэсире астында рус җәмагәт тормышында күтәрелеш сизелү вакты була. Яшьләр дәртләнеп фәнне өйрәнергә керешәләр, үз-үзләреннән уку белән шогыльләнәләр. Күптән түгел генә ачылган Казан университетында «барлык түбән һәм кабәхәт нәрсәгә тирән нәфрәт белән карау һәм барлык намуслы һәм югары нәрсәгә, гәрчә төптән уйланылмаган булса да, тирән ихтирам хөкем сөрә иде, — дип яза Аксаков үзенең «Семья хроникасы»нда. — Көндезен генә түгел, төннәр буенча да укыйлар. Бөтенесе ябыгып бетте, чырайлары үзгәрде һәм начальство мондый чиктән тыш атлыгуны бераз сүндерү өчен җидди чаралар күрергә мәҗбүр булды... Гүзәл, алтын вакыт! Белемнәргә саф мәхәббәт вакты, гадел мавыгу вакты».

Н. И. Лобачевскийнең математика фәннәре белән мавыгуы Казанга Европаның зур галимнәре — Бартельс, Броннер, Реннер һәм Литтровлар килү белән башлана. Алар Лобачевскийне астрономиядәге, физикадагы, математика һәм философиядәге алдынгы идеяләр белән таныштыралар, Бартельс һәм укытучы Гаусс[1] аңа аеруча тәэсир ясыйлар.

Бартельс бик шәп галим һәм педагог була. «Казан университетында математиканы укыту Бартельс аркасында бик тиз арада дөньяның иң яхшы университетларындагы укыту белән бер дәрәҗәгә менә. Математикада зур зирәклек күрсәткән Лобачевскийне ул башкалардан аерып ала һәм аны атнасына 4 сәгать өйдә дә укыта.

Студент Лобачевский Гауссның һәм Лагранжның[2] хезмәтләрен ентекләп өйрәнә, Бартельс заданиесе буенча математикадан үзенең беренче эшләрен яза. Фикер йөртүләрдә һәм нәтиҗә ясауларда Гаусс һәм Лагранж әсәрләренә хас булган таләп итүчәнлекне Лобачевский соңыннан үзенең тикшеренүләрендә дә куллана, Николай Иванович Лобачевский һәрвакыт фәнгә карата иң зур таләпләрне куя: «Фәннең башланып китә торган беренче тө-

[1] Гаусс, Карл Фридрих — (1777—1855) бөтен гасырларның иң бөек математикларыннан берсе.

[2] Лагранж Жозеф-Луи (1736—1813) атаклы француз математигы.

шенчәләре ачык булырга һәм иң кечкенә санга китерелгән булырга тиеш. Тик шул вакытта гына алар тагльиматның ныклы һәм җитәрлек нигезе булып хезмәт итә алалар»[1] дип раслый ул.

Казан университеты каршында астрономия обсерваториясе оештырган зур галим Литтров җитәкчелеге астында Н. И. Лобачевский астрономияне өйрәнә. Аның белән бергә ул 1811 нче елда кометага күзәтүләр үткәрә. Литтровның университет каршында чыгарыла торган «Казанские известия» дә басылган белдерүе Н. И. Лобачевскийнең гыйлми хезмәтләре турында мәтбугатта беренче хәбәр була.

Астрономия белән шогыльләнү геометриянең нигезләренә, бигрәк тә параллель сызыклар теориясенә карата кызыксыну тудыра. Соңыннан да, үзенең фәнни эшчәнлегенең бөтен дәвамында да, Лобачевский астрономия белән шогыльләнүен ташламый[2].

Бик күп төрле юнәлештәге китапларны зур кызыксыну белән укыган Лобачевский күп «ялган төшенчәләрне» үзләштерә һәм хәтта «шактый сизелерлек дәрәҗәдә динсезлек билгеләрен күрсәтә». Бу турыда 1811 нче елда инспектор Кондырев ректорга шулай хәбәр итә. Талантлы, ирек сөючән егет бу елны университетның реакцион кликасы тарафыннан «иң бозык холыклы» студент дип белдерелә. Лобачевский алдына университеттан куып чыгарылу куркынычы килеп баса, шуның өстенә тагын аны солдатка бирүләре дә мөмкин була. Нак шул елның язында Николай I нең түбәндәге указы чыга:

«Руханый һәм разночинец балаларыннан булган казна хисабына тәрбияләнүчеләрнең, университет студентларының һәм башка югары училищеләрдә укучыларның бозык холыклыларын һәм мөһим җинаятьләрдә тотылганнарын югарыда әйтелгән уку йортларыннан бөтенләй чыгарганнан соң, гаскәри хезмәткә җибәрергә, ә дворян балаларыннан булганнарын гали җәнапләре карамагына тапшырырга».

Ләкин Лобачевскийне университетның профессорлары яклап калдыра. Үзенең шәкертен университет Советында

---

[1] Әсәрләр җыентыгы. I т. 2 нче бүлек, 1883 ел, Казан.

[2] 1842 нче елда Лобачевский тулы кояш тотылуын күзәтү өчен Пензага бара. Үзенең анда баруы турында басылып чыккан отчетында кояш таҗының табигате һәм яктылык теориясе турында оригиналь карашлар яза.

яклаганда Бартельс аның аеруча сәләтлелеген мисал итеп ала: «Мин, — ди Бартельс әйтә, — курсны тәгәлләү алдыннан Лобачевскийгә Лагранж буенча әйләнә турында үзем эшләгән киң һәм авыр мәсьәләне минем җитәкчелегем астында чишүне тапшырдым. Бу турыдагы лекция Симонов тарафыннан язылган иде. Ләкин Лобачевский боларның берсеннән дә файдаланмады, соңгы лекцияне тәмамлаганда ул мәсьәләнең үзе эшләгән чишелешен бирде. Моны мин академик Вишневскийгә күрсәттем. Ул анардан таңга калды».

Ректорның каршы булуына карамастан, Лобачевскийнең укытучылары ходатайствосы аркасында университет Советы аңа математика фәннәренең магистры дәрәҗәсен бирергә мәҗбүр була. Профессорлардан Бартельс, Литтров, Герман һәм Броннер Советка тапшырган язуларында «математика һәм физика фәннәрендә Лобачевскийнең чиктән тыш зур уңышлары һәм шундый ук талантлыклары барлыгын» күрсәтәләр. Профессорларның Лобачевский турындагы шундый яхшы отзывлары булуга карамастан, Совет аны шулай да 1811 нче елның 3 нче августында магистр дәрәҗәсен алган вактында үзенең «начар холыкы»на карата тантаналы тәүбә итәргә һәм киләчәктә төзәлергә вагдә бирергә мәҗбүр итә.

Николай Иванович Лобачевский үзенең математика белән шогыльләнүен тагын да энергиялерәк рәвештә дәвам итә. Магистр булу ягыннан аның бурычлары исәбенә шулай ук «саф математика профессоры булган Бартельснең уңышларына, аның тыңлаучыларының зур уңышлары турында фикер йөртүдә булышуда һәм аларга аңламаган нәрсәләрен төшендерү» бурычлары да кертелә.

Лобачевскийнең педагогик эшчәнлеге 1812 нче елдан башлап киңәя башлый — аңа, классный чин алганда университет каршында экзамен тапшырырга тиеш булган чиновникларны арифметика һәм геометриядән укыту эше тапшырыла. Бер үк вакытта Н. И. Лобачевский фәнни эшен дә алып бара. 1814 нче елда ул адъюнкт булып раслана, ә 1816 нчы елда профессор исемен ала.

Университеттагы педагогик эшенең беренче елларында ук Лобачевский математика курсларының бер өлешен үз дәфтәрләре буенча укыта. 1815—1817 нче елларны ул геометриядән лекцияләр укый һәм Эвклидның [1] параллель

[1] Эвклид — безнең эрага чаклы өч йөз ел элек яшәгән борынгы грек галиме.

сызыклар турындагы бишенче постулатын исбат итәргә маташа, ләкин тиздән, галимнәр йөз еллар буена уңышсыз рәвештә баш ваткан бу мәсьәләне чишү бурычыннан баш тарта.

Безнең эра башланганга чаклы ук инде, Эвклидның борынгы грек комментаторлары параллель сызыклар теориясенә карата зур кызыксыну белән караганнар. V гасырда яшәгән грек математигы Прокл бу комментаторларның хезмәтләренең исемлеген бирә һәм үзенең фикерләрен яза. Гарәп математикларыннан бу өлкәдә галим Нассир-Эддин (XIII гасыр) аерылып тора. XVI—XVIII гасырларда бу проблема белән Европада галимнәрдән Клавий, иезуит Саккери һәм башкалар шогыльләнәләр. XVIII йөзнең ахрында һәм XIX йөзнең башында атаклы галимнәр Ламберт, Лагранж, Лаплас, Лежандр һәм В. Болиа параллель сызыклар теориясенә шактый зур игтибар бирәләр. Ел саен бу темага яңа берәр әсәр чыкмый калмый, ә кай арада елына берничә дә чыга, мәсәлән, 1786 нчы елда бу темага 7 хезмәт басылып чыга. Тора бара мондый хезмәтләрнең саны тагын да арта. 1813—1827 нче еллар дәверендә бер француз һәм немец телләрендә генә дә 30 лап хезмәт басыла. Аларның бер өлеше, Казан университеты көтепханәсе каталогының раславына караганда, Лобачевский тарафыннан сатып алына.

1792 нче елдан башлап параллель сызыклар проблемасы белән Гаусс кызыксына башлый, соңгы чиктә ул Эвклидның бу бишенче постулатын исбат итү мөмкин нәрсә түгел дигән карашка килә. 1816 нчы елда ул матбугатта түбәндәге белдерү белән чыга:

«Параллель сызыклар теориясен нигезләү турында геометрия башындагы пробел (җитешсезлек) хакында язылган кадәр күп язылган мәсьәләләр математика өлкәсендә бик аз. Бу пробелны тутырырга маташкан яңа хезмәт чыкмый калган ел бик сирәк була, ләкин шулай да без ачыктан-ачык намус белән икрар итәргә тиешбез — ике мең ел буена без бу мәсьәләдә Эвклиддан бер дә ары китә алмадык. Тутырырга хәлебездән килмәгән пробелны, тәнкыйт күтәрә алмаслык шикле дәлилләр челтәре астына яшерергә тырышуга караганда, читләтеп тормыйча һәм шушылай ачыктан-ачык итеп әйтеп бирү — безнең уебызча, фәнгә лаеклырак булыр».

Н. И. Лобачевский дә шундый ук фикергә килә. 1823

нче елда ул геометрия дәреслеге төзи һәм «тулы магнәдәге математик исбатлары булмау» сәбәпле бишенче постулатны исбат итү мөмкинлеген шушы дәреслектә катгый рәвештә кире кага. Николай Иванович фәнне нигезләүләргә аеруча каты таләпләр белән карый, фәннең төп фикерләре үтә ачык булырга, күп булмаска һәм үзләренең исбат ителүләре ягыннан бик аңлаешлы булырга тиешләр дип саный. Ә Эвклид геометриясе исә, аның уенча, «караңгы, хәтта ялган төшенчәләрдән» башлана.

«Пространство, сузылган ара, урын, җисем, өслек, сызык, нокта, юнәлеш, почмак — бу сүзләр белән геометрияне башлап җибәрәләр, ләкин бер вакытта да бу сүзләр белән ачык төшенчәне бергә кушмыйлар».

Лобачевский тарафыннан Математиканың нигез төшенчәләрен яңадан карау математика, астрономия һәм философиянең гомуми үсеше тәэсире астында башлана. Бу үсеш техника һәм практик тәҗрибәнең төгәл белемнәргә карата куйган таләпләренә бәйләнгән була. «Бу яктан XIX йөзнең башы бик характерлы вакыт булды. XIX йөздәге математиканың бөтен үсешенә хас булган ике юнәлешнең башланып киткән вакты шул. Бер яктан, машиналар уйлап чыгаруга бәйле физик һәм техник проблемаларда математиканы куллану үсә. Бу юнәлеш күп кенә бик шәп француз математиклары эшендә чагыла, ә Россиядә ул Остроградский һәм Чебышев исеме белән бәйләнгән. Ләкин математик анализның тагын да күбрәк катлауулануы һәм күбрәк кулланылуы белән бер рәттән фәннең нигезләрен яңадан тикшерү башлана. Гаусс һәм Коши, аннан соң аларның шәкертләре һәм, ниһаять, Вейерштрасс XIX йөз дәвамы буенча, абсолют җиддилекне таләп итеп, математиканың башлангыч положениеләрен тәнкыйтьлиләр һәм аның нигезләрен яңадан тикшерәләр. Бу агым XIX йөздә Гаусс тарафыннан башланды, ә аның иң күренекле вәкиле Лобачевский булды»[1].

1826 нчы елга кадәр Лобачевский математик фәннәрнең нигезләренә тирәнтен ентекләп тикшерү үткәрә, үзенең неэвклид геометриясе теориясен эшләп чыгара. Аның гыйлми эшчәнлеге шул вакытта башланган реакциянең авыр шартларында бара. Яшьләр арасында азатлык

---

[1] **Б. Кузнецов.** «Лобачевский һәм аның замандашлары». «Под знаменем марксизма» журналы, 7 нче китап, 1937 нче ел.

идеяләренең таралуыннан курыккан Александр I хөкүмәте 1818 нче елда училищеләрнең баш идарәсенә инструкция төзи. Бу инструкциядә хөкүмәт: «дин, эш йөртү һәм власть арасында даими һәм коткаручан татулык» булдыруны таләп итә. Хәлне тикшерү өчен Казан университетына атаклы мракобес Магницкий җибәрелә. Университет турында ул түбәндәге нәтиҗәгә килә: «профессорларның ышанычлы булмавы һәм куркыныч рух таралган булу» сәбәпле университет «юк ителергә тиеш. Аны юк итү ике төрле эшләнергә мөмкин: 1) университетны туктату юлы белән һәм 2) аны халык алдында җимерү юлы белән».

Патша хөкүмәте Казан университетын бөтенләй бетереп ташларга шулай да батырчылык итми, ләкин аны Магницкий кулына тапшыра. Университет тарихында «Магницкий эпохасы» дип исемләнгән атаклы эзәрлекләү эпохасы башлана. Иң яхшы профессорлар эштән куылалар, ханжество, ялагайлык, ярарга тырышучанлык урнаштырыла. Кафедралар өстенә дин китапларыннан алынган өзекләр язып элене. Гаепләнгән студентлар «гонаһлы кешеләр» дип исәпләнәләр. Аларны җәзалау өчен, дин китапларыннан алып язылган текстлар ябыштырылган һәм распятие[1] куелган тимер рәшәткәле бүлмә билгеләнә. Магницкийгә ярар өчен профессорлардан берсе математикадан үзенең лекцияләрен: «Алланың ярдәме белән, бу ике өчпочмак бер-берсенә тигез» дип башлый торган була. Лобачевский математикадан үзенең лекцияләрен укуны вакытлыча туктатып торырга мәҗбүр була. Магницкийнең чиркәү-полиция режимына, фәнне хурлавына җавап итеп, Лобачевский университеттагы тантаналы акт вактында речь сөйләүдән баш тартырга батырчылык итә.

Һәр җирдә, хәтта математикада да патша властенә каршылык эзләгән Магницкий Лобачевскийнең геометрия дәреслеген басып чыгаруны тыя, ул үзенең тыюын реакцион академик Фуссның фикеренә нигезли. Фусс Лобачевскийнең озынлык берәмлеге итеп метрны алуына һәм әйләнәне 400 градуска бүлүенә бик нык ачуланып, аның дәреслеген басуга каршы дәлиленең берсе итеп, түбәндәгене күрсәтә: «Ошбу бүлүнең француз револю-

[1] Распятие — куллары һәм аякларыннан тәрәгә кадакланган Христос сурәте.

циясе вактында уйлап чыгарылганы билгеле, ул чакта милләтнең искене юк итәргә шашынып омтылуы хәттә календарьгә һәм айләнәне бүлүгә чаклы барып җиткән иде, ләкин бу яңалык Франциянең үзендә дә күптән ташланды инде».

Неэвклид геометрияне ачуы турында Лобачевский 1826 нчы елның 12—24 нче февралендә физика-математика факультеты утырышында игълан итә. Лобачевский үзенең геометриясен, бирелгән туры сызыктан читтә алынган нокта аркылы, бирелгән туры сызык белән кисешмичә, яссылык өстендә исәпсез күп туры сызыклар уздырып була дип раслауга нигезли һәм бу раславы белән Эвклидның бишенче постулатын юкка чыгара. Бөтен положениеләре нык тәртипле булган, берсеннән-берсе логик рәвештә килеп чыккан гыйлми теориянең бик шәп системасы килеп чыга. Лобачевский үзенең геометриясен чынбарлыкның конкрет фактларына, ягни, каты җисемнәрнең яшәвенә, аларның хәрәкәтләнүенә, бер-беренә тиешүләренә һәм кисешеп бүлгәләнүләренә нигезли. «Бу фактлардан чыгып, — дип яза профессор А. Васильев,[1] — Лобачевский өслек турында, сызым, нокта турында төшенчәләр чыгара, сфераны барлык нокталары бер ноктадан тигез ераклыкта булган өслек итеп, түгәрәкне ике сфераны кисеп чыга торган сызык итеп, сызыклы почмакны — түгәрәк дугасы итеп, яссылыклы почмакны — сфераның бер өлеше итеп, яссылыкны — сфераларның кисешүеннән килеп чыккан түгәрәкләр яткан өслек итеп билгели һ. б.»

Пространство турындагы үзенең идеалистик тагълиматына нигезләп, геометрия тәҗрибәгә бәйле түгел дип игълан иткән Кантка каршы, Лобачевский философиянең һәм математиканың төп төшенчәләренә үзенең материалистик карашын раслый. Аның «Новые начала» дигән китабының кереш сүзендә түбәндәге юллар бар: «Табигатьтә без асылда, аннан башка тоею тәэсирләре мөмкин булмаган, хәрәкәтне генә танып беләбез. Шулай итеп, барлык башка төшенчәләр, мәсәлән, геометрия төшенчәләре, хәрәкәт сыйфатларында алынганлыктан, безнең акылыбыз тарафыннан ясалма рәвештә эшләнгәннәр, шуңа күрә пространство, үз алдына безнең өчен аерым

---

[1] «Неэвклид геометриянең йөз еллыгы» дигән җыентык. Казан, 1927 е.

яшәми». Ул үзе төзегән геометрик төшенчәләр дөньясының реаль булуына тирәнтен ышана, табигат белеме күрәешләрендә бу реальлекнең раслануын эзли. «Новые начала» дагы шул ук кереш сүзендә Лобачевский болай дип яза:

«Эвклид заманыннан бирле, ике мең ел дәвамында юкка тырышулар мине, төшенчәләрнең үзләрендә әле, кешеләр башка физик законнар шикелле итеп исбат итәргә һәм аңа ышанырга теләгән хәкыйкат юк дип, бу төшенчәләрдә, мәсәлән, астрономия күзәтүләре шикелле, бары тәҗрибәләр генә булырга мөмкин, дип шик тотарга мәҗбүр итте».

Лобачевский үзе ачкан таглимат белән галимнәрнең киң даирәсен таныштыру өчен бөтен юллар белән тырыша. Ул үзенең параллель сызыклар турындагы теориясе замандашларына аңлашылмас яки алар тарафыннан дошман караш белән каршыланыр дип курыкмый.

Лобачевскийнең неэвклид геометриясе математика фәннәренең үсешендә куәтле фактор булды, хәзерге көндә ул теоретик астрономиядә, механикада, физикада, хәтта инженерлык сәнгатендә дә кулланыла. 1893 нче елдан башлап, Казан университеты каршындагы физика-математика җәмгыяте тарафыннан, неэвклид геометрия буенча иң яхшы хезмәтләргә периодик рәвештә Лобачевский исемендәге халыкара конкурслар уздырыла. Бу конкурсларда дөньяның иң зур математикләры катнаша.

Үзенең күп яклы эшчәнлегендә Лобачевский Казан белән, Казан университеты белән тыгыз бәйләнгән. 1827 нче елдан башлап, 20 елга якын, Николай Иванович Лобачевский Казан университетының ректоры булып эшли. Ул йөрәгенең, бөек акылының бөтен дәртен, үзенең бөтен талчыгусыз энергиясен яшьләрне тәрбияләүгә, фәнне үстерүгә бирә. Үзенең шәкертләрендә ул җанлы фикер уята, халык өчен лекцияләр укуга, һөнәр мәктәпләрендә математика фәннәрен укыту проектларын төзүгә күп энергиясен куя.

«Тормыш ташкынын наданлык кыскан дәрәҗәдә кыскан башка бер нәрсә дә юк; ул тормышны бишектән алып кабергә чаклы үлек юл буйлап турыдан-туры озатып куя. Түбән язмышта да котылгысыз интектергеч хезмәтләре, ял итү белән бергә кушылып, игенченең, һөнәрченең акылын рәхәтләндерә: ләкин сез, гаделсез очрак аркасында яшәвегез башкалар җилкәсенә авыр салым булып

әверелгән кешеләр, сез, акылыгыз аңгыраланган һәм тойгыларыгыз сүнгән кешеләр, сез тормыштан тәм тапмыйсыз. Сезнең өчен табигать үлек, поэзиянең матурлыклары сезгә ят нәрсә, архитектураның гүзәллекләрен һәм сокландыргыч матурлыкларын сез күрмисез, гасырлар тарихы сезне кызыксындырмый. Мин, безнең университеттан үсемлек табигатенең мондый әсәрләре чыкмас, бәхетсезлеккә каршы, шундый булу өчен туган кешеләр булсалар да, алар хәтта монда кермәсләр дә, дигән фикер белән юанам. Кермәсләр, дип кабатлыйм, чөнки монда шөһрәт сөю, намус һәм эчке яхшылык хисе дәвам итә».

Николай Иванович Лобачевский әнә шулай дигән. Аның речененең бу кайнар сүзләрендә, «яшәүләре башкалар җилкәсенә авыр салым булган» кешеләргә карата чиксез дошманлык карашы һәм үз халкына кайнар мәхәббәт гәүдәләндерелгән сүзләрендә — үз ватанының дәртле патриоты һәм аның лаеклы улы — Лобачевский бөтенләе белән чагылган.

Патша хөкүмәте Лобачевскийнең кадрен белмәде, аның хезмәтләрен танымады. Министерстводагы бер серле интрига аркасында ул кафедрасыннан һәм ректорлыктан мәхрүм ителә. Бөтен тормышын фәнгә, университетка биргән Лобачевский өчен бу коточкыч авыр удар була, асылда ул аны яшәү средствосыннан мәхрум итә. Ауру килеш, ярым сукыр хәлендә Лобачевский неэвклид теориясе өстендә, университетта укыту эшен яхшырту өстендә тырышып эшләвен дәвам итә. Ул сүнеп барган күз карашын еракка текәгән хәлдә, башын горурлык белән югары күтәреп йөреп, үзенең сукырлыгын яшерергә тырыша. Сукыр көенчә ул лекцияләргә, экзаменнарга йөри, студентларның җавапларын тыңлый.

Лобачевский 1856 нчы елның 12 нче февралендә үлде.

Тик Совет илендә генә аның гүзәл идеяләре тулысынча танылуга ирештеләр. Советлар илендә Николай Иванович Лобачевскийне бөек галыйм итеп, фәннең һәм бөтен дөнья культурасының үсеше өчен батыр көрәшче итеп таныйлар һәм зур ихтирам белән искә алалар.

*В. Мартынов.*